# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**18 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 26 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыен нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы тозелде:

«2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку рәвешендә укучы студентлардан, өлешчә мобилизациягә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш бер тапкыр бирелә торган түләү, аны 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләде:

- Азнакай МР Мәсгут торак пунктындагы юлларны кардан чистарту;
- Мәсгут торак пунктында урамнарны яктырту өчен электр товарларын сатып алу;
- ТР Азнакай МР Мәсгутово торак пунктында зират коймасын алыштыру (сүтү, монтажлау, панельләр сатып алу) ;
- ТР Азнакай районы Мәсгут торак пунктының үзәкләштерелгән чыганагыннан эчәргә яраклы су анализы;
- ТР Азнакай МР Мәсгутово торак пунктында «Сабантуй» бәйрәмен оештыру һәм уздыру;
- МТЗ-82 өчен гидроповоротный пычак сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 264 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 167.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 167, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку рәвешендә укучы студентлардан, әлешчә мобилизациягә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш бер тапкыр бирелә торган түләү, аны 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләде:

- Азнакай МР Мәсгут торак пунктындагы юлларны кардан чистарту;
- Мәсгут торак пунктында урамнарны яктырту өчен электр товарларын сатып алу;
- ТР Азнакай МР Мәсгутово торак пунктында зират коймасын алыштыру (сүтү, монтажлау, панельләр сатып алу) ;
- ТР Азнакай районы Мәсгут торак пунктының үзәкләштерелгән чыганагыннан эчәргә яраклы су анализы;
- ТР Азнакай МР Мәсгутово торак пунктында «Сабантуй» бәйрәмен оештыру һәм уздыру;
- МТЗ-82 өчен гидроповоротный пычак сатып алу.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәсгут авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге башлыгы Д.З. Миннеханов